КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 29 март г.Казань № 285

2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасының территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын тормышка ашыру кысаларында мәҗбүри медицина иминияте буенча иминләштерелгән, шул исәптән яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) белән авыручы һәм (яки) аның белән авыруга шик булган затларга беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтүне өстәмә финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина фонды бюджетына бюджетара трансфертлар бирү буенча Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган, максатчан билгеләнешкә ия булган башка бюджетара трансферттан 2022 елда файдалану тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елда территориаль мәҗбүри медицина иминияте программаларын тормышка ашыру кысаларында мәҗбүри медицина иминияте буенча иминләштерелгән, шул исәптән яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) белән авыручы һәм (яки) аның белән авыруга шик булган затларга беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтүне өстәмә финанслар белән белән тәэмин итү өчен тиешле территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына бюджетара

трансфертлар бирү буенча Россия Федерациясе субъектларының һәм Байконур шәһәренең чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү максатларында, финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып Россия Федерациясе Хөкүмәте резерв фондының бюджет ассигнованиеләре торган Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына һәм Байконур шәһәре бюджетына федераль бюджеттан максатчан билгеләнешкә ия башка бюджетара трансферлар бирү кагыйдәләрен раслау турында» 2022 ел, 2 февраль, 88 нче карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасының территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын тормышка ашыру кысаларында мәҗбүри медицина иминияте буенча иминләштерелгән, шул исәптән яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) белән авыручы һәм (яки) аның белән авыруга шик булган затларга беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтүне өстәмә финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина фонды бюджетына бюджетара трансфертлар бирү буенча Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган, максатчан билгеләнешкә ия булган башка бюджетара трансферттан 2022 елда файдалану тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгын Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды тарафыннан бюджетара трансферт бирүгә заявка җибәрелә торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең вәкаләтле башкарма органы итеп билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 29 март, 285 нче
карары белән расланды

2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына
Татарстан Республикасының территориаль мәҗбүри медицина иминияте
программасын тормышка ашыру кысаларында мәҗбүри медицина иминияте буенча
иминләштерелгән, шул исәптән яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19)
белән авыручы һәм (яки) аның белән авыруга шик булган затларга беренчел
медицина-санитария ярдәме күрсәтүне өстәмә финанслар белән тәэмин итү өчен
Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина фонды бюджетына
бюджетара трансфертлар бирү буенча Татарстан Республикасы чыгым
йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү максатларында федераль бюджеттан
Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган, максатчан билгеләнешкә ия
булган башка бюджетара трансферттан 2022 елда файдалану
тәртибе

1. Бу Тәртип 2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасының территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын тормышка ашыру кысаларында мәҗбүри медицина иминияте буенча иминләштерелгән, шул исәптән яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) белән авыручы һәм (яки) аның белән авыруга шик булган затларга беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтүне өстәмә финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина фонды бюджетына бюджетара трансфертлар бирү буенча Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган, максатчан билгеләнешкә ия булган башка бюджетара трансферттан (алга таба – шул ук эзлеклелектә Фонд, башка бюджетара трансферт) 2022 елда файдалану кагыйдәләрен билгели.

2. Бюджетара трансферт акчасын тоту Фонд тарафыннан Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган шәхси счет аша гамәлгә ашырыла.

3. Фонд бюджетына бюджетара трансфертны күчерү 2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасының территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын тормышка ашыру кысаларында мәҗбүри медицина иминияте буенча иминләштерелгән, шул исәптән яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) белән авыручы һәм (яки) аның белән авыруга шик булган затларга амбулатор шартларда медицина ярдәме күрсәтүне өстәмә финанслар белән тәэмин итү өчен кирәкле акча күләмен раслый торган бюджетара трансфертлар бирүгә заявка нигезендә гамәлгә ашырыла.

4. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Фонд бюджетына Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан кертелгән бюджетара трансферт бирүгә заявка нигезендә 2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына

Татарстан Республикасының территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын тормышка ашыру өчен әлеге заявка кергән көннән биш эш көне эчендә 2022 елга Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре күләмнәре, расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан җиткерелгән иң чик финанслау күләмнәре чикләрендә бюджетара трансферт бирә.

5. Фонд:

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды тарафыннан расланган форма буенча бюджетара трансферт бирүгә заявка җибәрә;

2022 елда финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып бюджетара трансфертлар торган акчаны 2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасының территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын тормышка ашыру кысаларында мәҗбүри медицина иминияте буенча иминләштерелгән, шул исәптән яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) белән авыручы һәм (яки) аның белән авыруга шик булган затларга беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтү өчен медицина ярдәме күрсәтү һәм аны финанслар белән тәэмин итү күләмнәрен, срокларын, аның сыйфатын һәм шартларын контрольдә тоту нәтиҗәләре буенча «Россия Федерациясендә мәҗбүри медицина иминияте турында» 2010 елның 29 ноябрендәге 326-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан расланган Мәҗбүри медицина иминияте кагыйдәләрендә каралган тәртиптә түләүгә файдалана;

Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды тарафыннан билгеләнгән форма буенча, тәртиптә һәм срокларда Федераль мәҗбүри медицина иминияте фондына, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына бюджетара трансферттан файдалану турында, шул исәптән Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында башка бюджетара трансферт бирү турындагы килешүдә (алга таба – Килешү) билгеләнгән башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәсе мәгънәсенә туры килә торган бюджетара трансферт бирү нәтиҗәсе мәгънәсенә ирешү турында мәгълүмат бирелгән хисаплылык кертә.

6. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы:

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына Фондтан бюджетара трансферт бирүгә заявка кергән көннән биш эш көне эчендә Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды тарафыннан расланган форма буенча бюджетара трансферт бирүгә заявка җибәрә;

«Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасына Килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда түбәндәгеләрне тапшыра:

а) финанслар белән тәэмин итү максатларында бюджетара трансферт бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары турында хисап;

б) башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәсе мәгънәсенә ирешү турында хисап.

7. Фонд тарафыннан максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмаган бюджетара трансфертлар, алга таба Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә

федераль бюджет керемене күчерү максатларында, Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

8. 2022 елның 31 декабре хәленә карата Фонд тарафыннан бюджетара трансферт бирү нәтиҗәләре мәгънәләренә ирешү буенча йөкләмәләр бозылган һәм 2023 елда мондый мәгънәгә ирешү турында хисаплылык бирүнең беренче датасына кадәр әлеге бозулар бетерелмәгән очракта, алга таба федераль бюджетка күчерү өчен Фонд бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиешле акча күләме Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елда территориаль мәҗбүри медицина иминияте программаларын тормышка ашыру кысаларында мәҗбүри медицина иминияте буенча иминләштерелгән, шул исәптән яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) белән авыручы һәм (яки) аның белән авыруга шик булган затларга беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтүне өстәмә финанслар белән белән тәэмин итү өчен тиешле территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына бюджетара трансфертлар бирү буенча Россия Федерациясе субъектларының һәм Байконур шәһәренең чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү максатларында, финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып Россия Федерациясе Хөкүмәте резерв фондының бюджет ассигнованиеләре торган Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына һәм Байконур шәһәре бюджетына федераль бюджеттан максатчан билгеләнешкә ия башка бюджетара трансферлар бирү кагыйдәләрен раслау турында» 2022 ел, 2 февраль, 88 нче карарының 14 пункты нигезендә билгеләнә.

9. Бюджетара трансферттан файдалануны тикшерүдә тоту законнар белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.